**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ЗЕЛЕНОДОЛЬСКИЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ОЛЫ ҖӘКЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**РЕШЕНИЕ**
**КАРАР**

«26» март 2024 ел № 144

Җир эшләрен башкаруга рөхсәт бирү буенча Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының «Олы Җәке авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең вәкаләтләренең бер өлешен Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районына тапшыру турында.

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясының 4 өлешенә ярашлы рәвештә, Зеленодольск муниципаль районы Олы Җәке авыл җирлеге Советы карар итте:

1. Җир эшләрен башкаруга рөхсәт бирү буенча Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы муниципаль берәмлегенә Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районының Олы Җәке авыл җирлеге муниципаль берәмлегенең вәкаләтләренең бер өлешен тапшырырга.

2. Зеленодольск муниципаль районы Олы Җәке авыл җирлеге башкарма комитетына Зеленодольск муниципаль районы Башкарма комитеты белән килешү төзергә.

3. Вәкаләтләрнең бер өлешен гамәлгә ашыру ел саен Олы Җәке авыл җирлеге бюджетыннан Зеленодольск муниципаль районы бюджетына бирелә торган бюджетара трансфертлар хисабына башкарыла.

4. Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга (http://pravo.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районы сайты (http://zelenodolsk.tatarstan.ru шулай ук Олы Яке авылы, Школьная урамы, 1 йорт (администрация бинасы), Олы Яке авылы, Мәктәп урамы, la (КФҮ) адреслары буенча Олы Яке авылы мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә, Олы Яке авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Олы Җәке авыл җирлеге башлыгы
Совет рәисе: Ф. А. Фәйзуллина